| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ**<br>**ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ**<br>**БЕРӘМЛЕГЕ** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

5 апрель 2023 ел № 74

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 5 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законга (1 - 41 статья) ярашлы рәвештә, Сарман районы прокуратурасының 22.03.2023 елның 22-07-01/2023 номерлы протесты белән Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының 14.02.2022 ел, № 39 карарына, Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Шәрләрәмә авыл җирлеге советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 9.15 пункты. 9 нчы бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 4 нче пункт белән тулыландырырга:

"4) муниципаль хезмәткәрләрнең чит ил агенты статусын алулары.».

2. «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге
Советы рәисе Н.Н.Хуҗина